КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 ноябрь г.Казань № 1198

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 539 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада

мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 539 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 683 нче; 2021 ел, 23 сентябрь, 904 нче; 2022 ел, 22 август, 873 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «тәэмин итү» сүзләреннән соң «, мәдәни һәм аң-белем бирү программаларын иҗат итү һәм трансляцияләү» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта татар текстында «тәэмин итү» сүзләреннән соң «, мәдәни һәм аң-белем бирү программаларын иҗат итү һәм трансляцияләү» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, республикада мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, республика турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә татар текстында «тәэмин итү» сүзләреннән соң «, мәдәни һәм аң-белем бирү программаларын иҗат итү һәм трансляцияләү» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү» сүзләреннән соң «, мәдәни һәм аң-белем бирү программаларын иҗат итү һәм трансляцияләү» сүзләрен өстәргә;

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

3 пунктта «Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү» сүзләреннән соң «, мәдәни һәм аң-белем бирү программаларын иҗат итү һәм трансляцияләү» сүзләрен өстәргә;

9 пунктта:

беренче абзацта «Агентлыкның рәсми сайтында» сүзләрен «Агентлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – Агентлыкның рәсми сайты)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $15^1$ пункт өстәргә:

«$15^1$. Субсидия алу өчен субсидия алучы 2022 елда барлыкка килгән мәдәни һәм аң-белем бирү программаларын иҗат итү һәм трансляцияләү чыгымнарын каплау максатларында бу Тәртипнең 15 пунктында каралган документларны Агентлыкка тапшыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин